КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 15 август г.Казань № 581

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 12 февраль, 38 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 12 февраль, 38 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 27 июнь, 515 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 31 август, 746 нчы; 2013 ел, 14 март, 160 нчы; 2013 ел, 29 август, 611 нче; 2014 ел, 28 март, 194 нче; 2014 ел, 7 июнь, 388 нче; 2014 ел, 30 август, 630 нчы; 2015 ел, 21 октябрь, 789 нчы; 2015 ел, 29 декабрь, 1001 нче; 2016 ел, 7 октябрь, 725 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктның 3.3.1 пунктчасында:

сигезенче – унынчы абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«урманнардан файдалануны гамәлгә ашыручы гражданнар, юридик затлар тапшырган урманнардан файдалану һәм аларны саклау турында хисапларны карап тикшерә;

гражданнар, юридик затлар тапшырган урманнарны янгыннардан саклау турында хисапларны карап тикшерә;

урманнарны торгызуны һәм урман үрчетүне гамәлгә ашыручы гражданнар, юридик затлар тапшырган урманнарны торгызу һәм урман үрчетү турында хисапларны карап тикшерә;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«урманнарны пычранудан һәм башка тискәре йогынтыдан саклау чараларын гамәлгә ашыручы гражданнар, юридик затлар тапшырган урманнарны пычранудан һәм башка тискәре йогынтыдан саклау турында хисапларны карап тикшерә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфасын башкручы Р.К.Нигъмәтуллин